**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 27.06.2022** **№ 642**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү уздыру буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 28 февралендәге 398 номерлы карарына (26.03.2019 № 603 редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы, «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре хезмәт күрсәтүләренең сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 05 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын арттыру, гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү уздыру буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 28 февралендәге 398 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составы» 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Касюков Муса Нигъмәт улы | Мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе, Биектау муниципаль районының район Ветераннар оешмасы Советы рәисе |
| Газизов | Иҗтимагый Совет рәисе |

| | |
|---|---|
| Рафис Гарәфи улы | |
| Шакирова<br>Гөлсинә Шәфыйкъ кызы | Татар хатын-кызларының “Ак калфак” бөтендөнья иҗтимагый оешмасының Биектау бүлеге җитәкчесе |
| Гайфуллин Тәлгать Эдуард улы | Биектау мөхтәсибәтенең имам - мөхтәсибе |
| Нәҗметдинова Ләйсән Ринат кызы | Биектау муниципаль районы район оешмасының Хатын-кызлар Советы рәисе |
| Әхмәтҗанов Нияз Камил улы | Биектау муниципаль районының Әтиләр Советы рәисе |
| Вәлиуллина<br>Наталья Николаевна | «Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасының Биектау бүлеге рәисе |

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы бенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында: http://pravo.tatarstan.ru. веб адрес буенча игълан итәргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов